ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**04.02.2019**

Зеленодольск
шәһ.

**КАРАР**
**№ 256**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 25 июлендәге «Зеленодольск муниципаль районы мәктәпкәчә яшьтәге балалар оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2029нчы карары кушымтасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 30 декабрендәге «Татарстан Республикасы мәктәпкәчә яшьтәге балалар мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 1096нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы мәктәпкәчә яшьтәге балалар мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпләү буенча методик тәкъдимнәргә үзгәрешләр кертү турында 2018 елның 29 декабрендәге карарын башкару өчен, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР ИТӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы мәктәпкәчә яшьтәге балалар оешмаларында тәрбияләнүчеләрне карау һәм тәрбияләү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә норматив чыгымнарны исәплəү буенча методик тәкъдимнәргә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 25 июлендәге «Зеленодольск муниципаль районы мәктәпкәчә яшьтәге балалар мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында»гы 2029нчы карары белән расланган (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 13 октябрендәге 2595нче, 2018 елның 7 декабрендәге 2502нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән, 1.2нче пунктны «һәм Зеленодольск муниципаль районында мәктәпкәчә яшьтәге балалар гомуми белем бирү программасында гамәлгә ашырылган гомуми белем бирү оешмаларында балаларны тәрбияләү һәм карау өчен ата-аналар түләве » дигән сүзләр өстәп, үзгәреш кертергә.

2. Зеленодольск муниципаль район Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, масскүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә буенча бүлек җитәкчесе Анисимов Д.С.ка әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы информацион сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Зеленодольск муниципаль районы

Башкарма комитеты җитәкчесе Д.А. Сапожников